| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

25.07.2024 № 193/Бк/к

Опека, попечительлек (шул исәптән беренчел опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын башкарудан азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хокукка сәләтсез балигъ булган яисә тулысынча хокукка сәләтсез гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Хокукка сәләтсез балигъ булган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре хакында» 2024 елның 16 мартындагы 316 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 16 мартындагы 316 номерлы карары нигезендә ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 декабрендәге 400/Бк/к номерлы карары белән расланган опека, попечительлек (шул исәптән беренчел опека һәм попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз вазыйфаларын башкарудан азат итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4.1 пункт абзацында «15 көн эчендә» сүзләрен «10 эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 3.5.1. пунктның өченче абзацында «җиде көн эчедә» сүзләрен « алты эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 3.5.3. пунктның өченче абзацында «җиде көн эчедә» сүзләрен « алты эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 3.5.4. пунктның дүртенче абзацында «өч көн эчендә» сүзләрен «ике эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л. Н.Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов